ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙКОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21,e-mail:mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

Постановление **Карар**

№ 92 от «31» 01 2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районында җирләү буенча гарантияле исемлек
нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законы, "Күмү һәм җирләү эше турында" 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законы, "Татарстан Республикасында "Күмү һәм җирләү эше турында" Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында" 2007 ел, 18 май, 196 нчы карары", Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең "Айлык акчалата түләүләрне һәм компенсацияләрне индексациялә коэффициентын раслау" турында 2018 елның 26 нчы гыйнвары, 74 нче санлы карары нигезендә,Татарстан Республикасы Мамадышмуниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1.Мамадыш районында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1нче һәм 2нче кушымталар нигезендә 5701,31 сум күләмендә билгеләргә һәм 2018 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының2017 елның 31 нче гыйнварындагы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында" 85 нче санлы карарын 2018 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче И.М. Дәржеманов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
31.01.2018 ел, 92 нче номерлы карарына
кушымта №1

Татарстан Республикасы Мамадышмуниципаль районында
җирләү буенча гарантияле исемлекнигезендә
хезмәт күрсәтү бәясе
(тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булган очракта)

Хезмәт күрсәтү атамасы	Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)
Җирләү өчен документлар әзерләү	0,00
Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә	2622,62
Мәетне (мәет калдыкларын) алып килүгә	683,37
Кабер казу һәм җирләү	2395,32
барлыгы	**5701,31**

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
31.01.2018 ел, 92 нче номерлы карарына
кушымта №2

Татарстан Республикасы Мамадышмуниципаль районында
җирләү буенча гарантияле исемлекнигезендә
хезмәт күрсәтү бәясе
(тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта)

Хезмәт күрсәтү атамасы	Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)
Җирләү өчен документлар әзерләү	0,00
киендерү	813,65
Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә	1883,44
Мәетне (мәет калдыкларын) алып килүгә	697,20
Кабер казу һәм җирләү	2307,02
барлыгы	**5701,31**